РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ГЛАВА МЕШИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422062, Республика Татарстан, Сабинский район,
п. Лесхоз, ул Кукморская, 2а
тел. (84362)44-2-19

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МИШӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

422062, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Лесхоз бистәсе, Кукмара урамы, 2а йорт

тел. (84362) 44-2-19

e-mail: Mesh.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР
22.07.2024 №1

ТР Саба муниципаль районы Мишә
авыл җирлеге Башлыгының «Мишә
авыл җирлеге Советы вазыйфаи затларының
гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм
шәхси кабул итү тәртибен раслау турында»
16.03.2016 №2 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Район прокуратурасының 13.07.2024 № 02-08-01-2023/Прдп309-24-20920031 протесты нигезендә

Карар итәм:

1. Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге башлыгының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге Советы вазыйфаи затларының гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибен раслау турында» 16.03.2016 №2 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мишә авыл җирлеге Советы вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибен раслау тәртибенә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 7.2 пунктта "электрон адрес" сүзен "дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы "федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланганда"электрон почта адресы яки шәхси кабинет адресы (уникаль идентификатор)" сүзләре белән алыштырырга;

1.2. 7.3 пунктта "электрон почта адресы» сүзләрен “электрон почта адресы яки бердәм порталда шәхси кабинет адресы" сүзләре белән алыштырырга;

1.3. 14.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“14.9. Гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә органнарда чираттан тыш шәхси кабул итү хокукына I, II төркем инвалидлар, инвалид балалар һәм мондый балаларны озата баручы затлар ия.

Гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә органнарда беренче чиратта шәхси кабул итү хокукына ия:

1) Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары, хәрби хәрәкәтләр ветераннары;

2) ятим балалар, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар, шулай ук аларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре, әгәр алар мондый балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау белән бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

3) I, II төркем инвалидларның, инвалид балаларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре, әгәр алар инвалидларның, инвалид балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау белән бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

4) Өч яшькә кадәрге балалар белән кабул итүгә килгән гражданнар.

1.4. 18 пунктның 5 пунктында" Электрон почта адресы буенча күрсәтелгән" сүзләрне “электрон почта адресы буенча яки шәхси кабинет адресы буенча күрсәтелгән"сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы А. Х.Гатиятуллин